**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**«09 » 06 2023 ел** **№ 164**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында» 08.09.2020 №236 карарына үзгәрешләр кертү хакында (25.05.2021 №117, 23.07.2021 №165, 28.07.2021 №169, 20.09.2021 №204, 15.12.2021 №325, 25.03.2022 №98, 18.04.2022 №122, 29.07.2022 №202, 16.09.2022 №257, 21.12.2022 №402 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 статьясына үзгәреш кертү турында» 28.05.2022 №144-ФЗ Федераль Законга, «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәлек алып бару һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турындагы, 14.07.2022 №312-ФЗ, шулай ук «Җир кишәрлеген сатып алу турында" (А-0016) карар кабул итү һәм «Муниципаль хезмәтләр исемлегеннән чыгару турындагы» 02.08.2022 №04-51/5273 Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының хатын үтәү йөзеннән Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында» 08.09.2020 №236 карары белән расланган, Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген милеккә, арендага бирү, даими (сроксыз) файдалану, аукционнар үткәрмичә түләүсез файдалану буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (25.05.2021 №117, 23.07.2021 №165, 28.07.2021 №169, 20.09.2021 №204, 15.12.2021 №325, 25.03.2022 №98, 18.04.2022 №122, 29.07.2022 №202, 16.09.2022 №257, 21.12.2022 №402 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 2.6.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 31 пунктчасы белән тулыландырырга:

"31) милли парк чикләрендә урнашкан һәм килешүдә каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле Федераль милектә булган җир участогына карата милли паркта рекреацион эшчәнлекне гамәлгә ашыру турындагы килешү».

1.2. Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген милеккә, арендага бирү, даими (сроксыз) файдалану, түләүсез файдалану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә 35.1 пункты белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарның 1.1. һәм 1.2. пуктчалары 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов

Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген милеккә бирү, арендага бирү, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану, түләүсез файдалану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

**Гариза бирүченең аукцион үткәрмичә җир кишәрлеге алу хокукын раслаучы документларның исемлеге**

| № | Сатулар үткәрмичә җир кишәрлеген бирү | Җир кишәрлеген бушлай яки түләүле бирү хокукы төре | Гариза бирүче | Җир кишәрлеге | Гариза бирүченең җир кишәрлеген аукционнар үткәрмичә сатып алу хокукын раслаучы һәм җир кишәрлегенә хокуклар алу турындагы гаризага кушылган документлар төп нөсхәдә (күчермәдә, әгәрдә документлар һәркем өчен мөмкин булган) яки башкарма хакимият органы яки җирле үзидарә органы вазыйфаи заты тарафыннан расланган күчермәдә, яисә җир кишәрлегенә хокуклар алу турында гариза кабул итүче күчермәләрдә тапшырыла (җибәрелә) |
|---|---|---|---|---|---|
| 35.1 | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктының 23.3 пунктчасы | Арендага | Рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында килешү төзелгән юридик зат, шәхси эшмәкәр | Рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында килешүдә каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир кишәрлеге | Рекреацион эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү.<br>* Күчемсез милек объекты (сорала торган җир кишәрлеге) турында ЕГРН |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | нан өземтә<br>* Күчемсез милек объекты (сорала торган җир кишәрлеге) турында ЕГРНнан өземтә |